СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

(8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22,chishma@tatar.ru

**Татарстан Республикасы**
**Яңа Чишмә муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

**2017 елның «27» июненнән** **№ 27-141**

**2017 елның беренче яртыеллыгында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә ветераннарның, өлкән яшьтәге гражданнарның социаль-икътисадый хәлен яхшырту, аларның сәламәтлеген ныгыту һәм актив озак яшәүгә ярдәм итү буенча мәгълүмат**

Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары В.Н.Семенякның 2017 елның беренче яртыеллыгында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә ветераннарның, өлкән яшьтәге гражданнарның социаль-икътисадый хәлен яхшырту, аларның сәламәтлеген ныгыту һәм актив озак яшәүгә ярдәм итү буенча мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2017 елның беренче яртыеллыгында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә ветераннарның, өлкән яшьтәге гражданнарның социаль-икътисадый хәлен яхшырту, аларның сәламәтлеген ныгыту һәм актив озак яшәүгә ярдәм итү буенча мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына:

2.1. Квартал саен өлкән яшьтәге гражданнар белән спорт чаралары, иҗади фестивальләр һәм түгәрәк өстәлләр оештырырга;

2.2. Өлкән яшьтәге гражданнарны сыйфатлы азык-төлек белән тәэмин итү максатыннан сентябрьдән майга кадәр азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарларны арзан бәядән сату буенча атналык ярминкәләр оештырырга.

3. Яңа Чишмә муниципаль районында Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлегенә, Яңа Чишмә муниципаль районында «Забота» КЦСОНына:

3.1. Кирәкле ярдәм күрсәтү максатыннан, ай саен өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның, шулай ук социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ булган кешеләрнең яшәү шартларын тикшерергә;

3.2. Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә «Өлкән кешене тәрбиягә алучы гаилә» пилот проектын гамәлгә ашыруны, «Өлкән кешене тәрбиягә алучы гаилә» стационарны алмаштыручы технологияне кертүне тәэмин итәргә.

4. «Новошешминская РҮХ» ДАССО 2017 елның декабренә кадәр ветераннар өчен палаталарны кирәкле җиһазлар һәм карау әйберләре белән тәэмин итәргә тиеш.

5. Әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының социаль, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә**
**муниципаль районы Башлыгы** **В. М. Козлов**